**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**23.04.2024 ел** **№ 122**

**"Җир салымы турында" 2023 елның 24 октябрендәге 109 номерлы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2023 елның 24 октябрендәге 109 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертергә, аны түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1. 2024 елда салымнан азат ителәләр:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәт ярдәме инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында" 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы карары нигезендә кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәт ярдәме инфраструктурасының аккредитацияләнгән субъектлары реестрына кертелгән сәнәгать (индустриаль) парклары урнашкан һәм эшчәнлек алып барган җир кишәрлекләре хуҗалары.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Совета Рәисе Д.А. Ишкинеев